**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итү турында**

Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы оешуның Татарстан Республикасы күпмилләтле халкы дәүләтчелеге үсеше өчен зур тарихи һәм иҗтимагый-сәяси әһәмияткә ия булуын истә тотып, **карар бирәм:**

1. 2020 елда Татарстан Автоном Совет Социалистик Республикасы (алга таба – Татарстан АССР) оешуга 100 ел тулуга багышланган юбилей чаралары уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

өч ай вакыт эчендә Татарстан АССР оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә;

Татарстан АССР оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне әзерләү һәм уздыруны тәэмин итү буенча башка кирәкле чаралар күрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан АССР оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүдә катнашырга һәм аңа булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан АССР оешуга 100 ел тулуны бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 25 сентябрь
№ ПУ-930